**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КАЛМИЯ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТ ҖИТӘКЧЕСЕ**

# КАРАР

«27» июнь 2016 ел Калмия авылы № 58

Калмия авыл җирлеге Башкарма
комитеты җитәкчесе карарларының
үз көчләрен югалтуын тану турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Калмия авыл җирлеге уставына таянып, «Татарстан Республикасында шәһәр һәм авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары арасында вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2015 елның 26 декабрендәге 108-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законын 2016 елның 1 гыйнварыннан кертү нигезендә:

## КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге башкарма комитеты Җитәкчесенең «Муниципаль милектә булган гражданнарга социаль наем шартнамәсе нигезендә торак урыннары бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 15.02.2013 ел, № 4 карары үз көчен югалткан дип танырга.
2. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең «Социаль наем шартнамәсе нигезендә гражданнарга муниципаль милектәге торак урыннары бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2013 ел, 27 февраль, № 6карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге башкарма комитеты Җитәкчесенең «Муниципаль учреждениегә оператив идарә итү (түләүсез файдалану яки хуҗалык алып бару) хокукында муниципаль мөлкәтне (төзелмәләрне, корылмаларны) рәсмиләштерү (беркетү) буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2013 ел, 21 февраль, № 6 карары үз көчен югалткан дип танырга.
4. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Калмия авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге милкендә булган тарихи һәм мәдәни ядкярләрне файдалануга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2013 ел, 18 февраль, № 5 карары үз көчен югалткан дип танырга.
5. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге башкарма комитеты Җитәкчесенең «Муниципаль берәмлек

территориясендә реклама конструкциясен урнаштыруга, мондый рөхсәтләрне юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2013 ел,12 февраль, № 3 карары үз көчен югалткан дип танырга.

6. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында» 2013 ел, 10 июнь, № 10 карары үз көчен югалткан дип танырга.

7. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе карары белән расланган күчемсез милек объектының адресын бирү (үзгәртү, аныклау, юкка чыгару) буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 1.1 п.үз көчен югалткан дип танырга.

8. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең»Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру буенча административ регламентны раслау турында» 2013 ел, 14 март, № 91 карарына үзгәрешләр кертү хакында» 27.05.2014 ел, № 6 карары үз көчен югалткан дип танырга.

9. Татарстан Республикасы Калмия авыл җирлеге башкарма комитеты Җитәкчесенең «Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген аукцион формасында үткәрелә торган сатуларда җир кишәрлеген сату юлы белән милеккә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 ел, 24 декабрь, № 35 карары үз көчен югалткан дип танырга.

10.Татарстан Республикасы Калмия авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең «Гражданнарның коммерциягә карамаган бакчачылык, яшелчәчелек, дача берләшмәсе әгъзасы булган гражданга җир кишәрлеген түләүсез бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 ел, 24 декабрь, № 37 карары үз көчен югалткан дип танырга.

11.Татарстан Республикасы Калмия авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең «Гражданнарның коммерциягә карамаган бакчачылык, яшелчәчелек, дача берләшмәсе әгъзасы булган гражданга җир кишәрлеге схемасын раслау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 ел, 24 декабрь, № 36 карары үз көчен югалткан дип танырга.

12.Әлеге карарны районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

13.Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе Н.Р. Гыйлфанов